**«Килешәм»**
«Сэлэт» проектларның
җитәкчесе

Әдип Әлмир

_______________ 2022 ел

**«Раслыйм»**
«Сэлэт» ТРЯИФ
Генераль директоры,

Э.Р. Насибуллина

_______________ 2022 ел

НИГЕЗЛӘМӘ

М. И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбенең VII Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. М.И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбенең VII Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе (алга таба – Конференция) Татарстан Республикасы «Сэлэт» яшьләр иҗтимагый фонды (алга таба – «Сэлэт» ТРЯИФ) тарафыннан «Сэлэт» яшьләр үзәге дәүләт бюджет учреждениясе (алга таба – ЯҮ «Сэлэт») белән берлектә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Казан федераль (Идел буе) университеты катнашында үткәрелә.

1.2. Конференция фәнни эшләр конкурсы буларак карала, фәнни эшләр бер яки берничә автор тарафыннан башкарыла һәм экспертлар советы тарафыннан бәяләнә. Нәтиҗәләр конференция ахырында ясала һәм тантаналы рәвештә игълан ителә.

1.3. Конференциянең методик һәм оештыру мәсьәләләрен «Сәләт» ТРЯИФ хәл итә.

1.4. Конференциянең максаты – Татарстан Республикасы мәктәп укучыларының фәнни потенциалын үстерү.

1.5. Конференциянең бурычлары:
- фән юнәлешендә сәләтле укучыларны билгеләү;
- иҗади һәм интеллектуаль ярыш аша укучыларны төрле фән өлкәләренә җәлеп итү, кызыксындыру, активлаштыру;
- интеллектуаль-иҗади эшчәнлекне популярлаштыру, укучылар арасында фундаменталь һәм гамәли фәннәргә кызыксыну тудыру;

- фәнни тикшеренүләргә кызыксыну уяту, катнашучыларны төрле юнәлештәге фәнни мәктәпләргә җәлеп итү (математика, информатика, лингвистика, медицина, икътисад, биология, археология);
- фәнни-тикшеренү институтлары, югары уку йортлары галимнәрен мәктәп укучылары белән фәнни эшләр башкаруга җәлеп итү, үз фәннәренә карата балаларда кызыксыну уяту мөмкинлекләре тудыру;
- мәктәп укучылары башкарган фәнни эшләрнең җитәкчесе, яисә консультанты буларак катнашучы укытучыларның фән белән кызыксынуын арттыру һәм фәнни активлыгын үстерү;
- укыту процессында укучыларның фәнни тикшерү эшчәнлекләренә бәйле мәгариф программаларын һәм методикаларын үстерү;
- татар телен фундаменталь һәм гамәли фәннәр өлкәсендә актив куллану өчен мотивацион шартлар тудыру.

## 2. Фәнни юнәлешләр

2.1. Конференция түбәндәге юнәлешләрдә уздырыла:

2.1.1. Галәм, Җир шары һәм табигатькә караган фәннәр (*физика*, *химия, биология, экология*).
2.1.2. Кеше һәм җәмгыять турындагы фәннәр (*икътисад*, *социология, психология, татар теле*, *тарих*).
2.1.3. Тасвирлау, модельләштерү фәннәре һәм гамәли фәннәр (*семиотика, математика, информатика*).

## 3. Конференциядә катнашучылар һәм эшләрне тәкъдим итү тәртибе

3.1. Конференциядә Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 8-11-нче сыйныф укучылары катнаша ала. Эш индивидуаль фәнни-тикшеренү проекты буларак, яисә берничә автор тарафыннан (3 кешедән артык түгел) тәкъдим ителә ала; фәнни җитәкче белән берлектә язылырга тиеш.

3.2. Конференциядә катнашу өчен 2022-нче елның 28-нче февральдән алып 15-нче апрельгә кадәр selet.biz сайтында теркәлергә һәм fansar@selet.biz электрон почтасына фәнни-тикшеренү эшенең тезисларын җибәрергә кирәк (һәрбер кәгазь бите аерым файл буларак беркетелергә һәм авторларның фамилияләре күрсәтелергә тиеш).

3.3. Конференциягә тапшырылган фәнни эшләр «Антиплагиат» системасында тикшерелә. Текстның авторлык (оригиналь) өлеше 70% -тан ким булмаска тиеш. Шартлар үтәлмәгән очракта, фәнни эш эксперт советы әгъзалары тарафыннан тикшерелмиячәк.

3.4. Фәнни эшнең тезисларын 1-нче кушымтада язылган таләпләр нигезендә тутырыга кирәк. Әдәбият исемлеген, шәрехләмәләрне күрсәтмичә тезисларда кыскача формада фәнни эшнең төгәл эчтәлеге билгеләнә.

3.5. Фәнни эшнең тутырылу таләпләре 2-нче кушымтада билгеләнгән. Тикшеренү эше 25 бит күләменнән артырга тиеш түгел (кушымталар тикшеренү эшенең битләр санына керми).

3.6. Тикшеренү эшләре Нигезләмә шартларына туры килмәгән очракта, Оештыру комитеты андый эшләрне Конкурска алмаска мөмкин.

3.7. Конкурсның Оештыру комитеты материалларның исемен һәм эчтәлеген тезислар җыентыгына бастырырга теләгән очракта, авторлар ризалыгы белән аларны төзәтергә, яисә тезисларны бөтенләй кертмәскә дә хокуклы.

3.8. Тикшерү эшләренең электрон формасын, 4-нче кушымта нигезендә рәсмиләшереп, Оештыру комитетына PowerPoint яки PDF форматында тапшырырга кирәк. Тапшырылган презентация эчтәлеге экспертлар советы әгъзалары тарафыннан бәяләнә.

**4. Конференция уздыру һәм эшләрне тапшыру тәртибе**

4.1. Конференцияне уздыру өчен Оештыру комитеты, фәнни тикшерү эшләрен сайлау өчен Программа комитеты җавап бирә. Оештыру һәм программа комитеты составын, шулай ук, экспертлар советын «Сәләт» ТРЯИФ генераль директоры раслый.

4.2. Конференциянең уздыру вакыты һәм урыны.

| Вакыты | Чара | Уздыру урыны |
|---|---|---|
| Читтән торып катнашу этабы | | |
| 28.02.2022 – 15.04.2022 | Конференция катнашучыларының электрон теркәлүе | www.selet.biz |
| 28.02.2022 – 15.04.2022 | Гаризалар, тикшерү эшләре, тезислар кабул итү (электрон теркәлүдән соң гына) | fansar@selet.biz |
| 15.04.2022 – 22.04.2022 | Конференциянең читтән торып катнашу этабы | Сәләт йорты (Казан шәһәре, Островский ур., 23 йорт) |
| 22.04.2022 | Читтән торып катнашу этабының нәтиҗәләрен тәкъдим итү | www.selet.biz |

| Экспертлар составы каршында эшне тәкъдим итү этабы | | |
|---|---|---|
| 30.04.2022<br>10.00 – 11.00 | Конференция катнашучыларын теркәү | Сәләт йорты (Казан шәһәре, Островский ур., 23 йорт) |
| 30.04.2022<br>11.00 | Конференция ачылышы һәм пленар утырыш | |
| 30.04.2022<br>11.30-16.00 | Конференция секцияләренең эшләве | |
| 30.04.2022<br>16.00 | Конференциянең ябылу тантанасы. Катнашу сертификатларын тапшыру, җиңүчеләрне бүләкләү | |

4.3. Конференциядә автордашлар булуына да карамастан, экспертлар советы каршында эшне бер укучы (автор) тәкъдим итә.

4.4. Доклад Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә тәкъдим ителә ала – татарча яки русча. Әгәр доклад рус телендә сөйләнелә икән, эшне тәкъдим итү (презентация) татар телендә булырга тиеш.

4.5. Секцияләрдә чыгыш ясау өчен докладчыга 5 минут вакыт бирелә. Чыгыш ясау вакытында катнашучы үзенең кыскача, әмма тулы рәвештә тикшерү эшенең эчтәлеген сөйләп бирә. Ачыклап күрсәтү материаллары, плакатлар, таблицалар һәм санак кулланылырга мөмкин.

4.6. Докладны тикшергәндә эксперт советы әгъзалары һәм барлык тыңлаучылар дә катнаша ала (3 минут).

4.7. Конференция үткәрелү көнне катнашучылар 300 (Өч йөз) сум оргвзнос түлиләр.

5. **Эшләрне тапшыру һәм тикшерү тәртибе экспертлар советы секциясендә карала**

5.1. Эшләрне бәяләү һәм тикшерү ике этапта уза:

5.1.1. I этап (читтән торып катнашу): конкурста катнашкан фәнни эшләрнең Оештыру комитеты тарафыннан барлык кагыйдәләр нигезендә эшләнгәнлеге тикшерелә, шуннан соң фәнни эшләр эксперт советына җибәрелә.

5.1.2. I этапта экспертлар советы тарафыннан иң яхшы эшләр сайлап алына. Сайлап алынган эшләр 15-тән дә артык булмаска тиеш. Катнашучыга 3

көннән дә калмый электрон почта аша яки башка юл белән конференциянең икенче этабына чакыру җибәрелә.

5.1.3. II этап: Конференциянең II этабында сайлап алынган иң яхшы фәнни эшләр конференциянең эспертлар составы каршында эшне тәкъдим итү этабында катнаша.

5.1.4. Конференция дәвамында экспертлар советы өчтән да артык булмаган иң яхшы тикшеренү эшләрен сайлый.

5.1.5. Секциянең экспертлар советы фәнни эш авторын махсус бүләк белән бүләкли ала (бер юнәлештә бер махсус бүләк).

**6. Бүләкләү тәртибе**

6.1. Экспертлар советы киңәше нигезендә җиңүчеләргә һәм лауреатларга махсус дипломнар, мактау кагазләре, истәлекле бүләкләр тапшырыла.

6.2. Конференциянең барлык катнашучыларына Конференциядә катнашу сертификатлары бирелә.

**7. Оештыру комитеты белән элемтәгә керү өчен мәгълүмат**

7.1. Оештыру комитеты адресы: Сәләт йорты, Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт. Электрон почта: fansar@selet.biz. Белешмә өчен телефон: +7 834 292 16 00.

**8. Конференцияне финанслау**

8.1. Оештыру чыгымнарын финанслау «Сәләт» ТРЯИФ тарафыннан башкарыла.

Кушымта 1
М. И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбенең
VII Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе

**Тезисларны рәсмиләштерү һәм тәкъдим итү таләпләре**

Тезисларда шәрехләмәләр һәм әдәбият исемлеген кертмичә, кыска формада тикшеренү эшенең төп эчтәлеге тасвирлана.

1. Таблицаларның, схемаларның, рәсемнәрнең исемнәрен күрсәтү зарури. Алар OS Windows формасында язылырга тиеш.
2. Бит форматы: А4.
3. Чикләр: өс – 2 см, ас – 2 см, уң – 2 см, сул – 2 см.
4. Хәреф язылышы: Times New Roman, кегль – 12.
5. Юл арасы: берле интервал.
6. Кызыл юлның башлану чиге: 1 см.
7. Текстны тигезләү: бит киңлеге буенча.
8. Чик контурлары китерелми.
9. Тезислар Times New Roman хәрефе белән бастырыла (12 пункт, калын) һәм үзәк буенча тигезләнә. Юл уртасында урнашкан бүлек башына нокта куелмый.
10. Доклад исеме астында: Авторның фамилиясе һәм исеме (тулысынча языла) (11 пункт). Мәктәп, сыйныф, шәһәр.
12. Фәнни җитәкченең (укытучының) фамилиясе, исеме, әтисе исеме.
13. Түбәндә авторның уку оешмасының тулы исеме (курсив хәрефе белән).
14. Кызыл юлдан соң бер арадан тезислар материалы урнаштырыла.
15. Тезислар исеме, авторлар, мәктәп һәм сыйныф, фәнни җитәкче текстлары һәм төп текст араларындагы ераклык бер интервалга тигез. Мәктәп, сыйныф һәм фәнни җитәкче төрле юлдан билгеләнә.
16. Тезилар текстының күләме: А4 форматында 1 басма бит.

Кушымта 2
М. И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбенең
VII Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе

Тикшеренү эшен рәсмиләштерү һәм тәкъдим итү таләпләре

I. Тикшеренү эше структурасы

1. Тикшеренү эше фәнни эшләр өчен кабул ителгән билгеле бер тәртип буенча төзелә.

2. Структураның төп элементлары: баш бит, эчтәлек, кереш, төп өлеш, йомгак, әдәбият исемлеге, кушымталар.

a) Баш бит тикшеренү эшенең беренче бите булып санала һәм үрнәк буенча тутырыла (Кушымта 3). Тикшеренү эшенең баш бите ике телдә: татар һәм рус телләрендә бастырыла (секцияләргә карамастан). Титул биттә фәнни эшнең исеме татарча, русча, инглизчә язылырга мөмкин.

b) Баш биттән соң эчтәлек килә, эчтәлектә фәнни эшнең бүлекләре һәм битләре языла.

c) Фәнни эшнең кереш өлешендә сайлап алынган теманың актуальлеге, максаты, куелган бурычларның эчтәлеге, эзләнүнең объекты һәм предметы, методы, теоретик әһәмияте һәм килеп чыккан нәтиҗәләрнең кыйммәте күрсәтелә.

d) Фәнни эшнең төп өлешендә тикшерү эшенең методикасы һәм техникасы күрсәтелә һәм нәтиҗәләре йомгаклана. Эчтәлекне аңлатуга ярдәм иткән күрсәтмә материаллар кушымтада бирелә. Бүлекләр эчтәлеге фәнни тикшерү темасына төгәл туры килергә һәм теманы ачып бирергә тиеш. Әлеге бүлекләр тикшерүченең материалны логик һәм кыскача тәкъдим итү сәләтен күрсәтә.

e) Фәнни тикшерү эшенең йомгак өлешендә төп мәгънә һәм нәтиҗәләр күрсәтелә.

f) Тикшерү эше ахырында әдәбият исемлеге күрсәтелә. Текстта фәнни чыганакларны күрсәтүче сылтамалар да булырга мөмкин (чыганакның сылтама номеры әдәбият исемлеге белән туры килергә тиеш)

g) Кушымтада ярдәмче, яки өстәмә материаллар куела. Шулай ук өстәмә таблицалар, графиклар, рәсемнәр һ.б. күрсәтергә мөмкин.

II. Фәнни тикшерү эшен тутыру тәртибе

1. Тикшерү эшенең титул бите үрнәк буенча төзелергә тиеш (Кушымта 1.3.).

2. Тикшерү эше тәртип буенча бастырыла. Төрле текст өстәмәләре кертелми.

3. Форматлау тәртибе:

a) Тикшерү эшенең тексты Times New Roman хәрефе белән бастырыла (14-нче пункт), чикләре: сул – 3см (30 мм), уң – 1,5 см (15мм), өс – 2 см (20мм), ас – 2 см (20 мм). Текстны бит киңлеге буенча тигезләү зарури. Юл арасы 1,5 интервалында булырга тиеш. Чик контурлар китерелми.

b) Кызыл юл 1 см буш арадан башланырга тиеш.

c) Бүлек исеме белән текст арасында интервал 3-кә тигез. Бүлек исеме һәм параграф арасында да шушы интервал саклана. Юл уртасында язылучы бүлек

исеме ахырында нокта куелмый. Бүлек исеме астына сызу һәм юлдан-юлга күчерү тыела.
4. Фәнни-тикшеренү эше үтә күренмәле өске бит белән махсус папкага урнаштырыла (эшне файлларга урнаштыру тыела; файлларда бары тик фотосурәтләр, гербарийлар һ.б.ш. кушымта битләре генә булырга мөмкин). Программа белән диск аерым файлга урнаштырыла һәм беркетелә.

Кушымта 3
М. И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбенең
VII Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе

**Баш битне тутыру таләпләре**

М. И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбенең Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе

Фәнни юнәлеш: 2.1.1. Экология
Тикшеренү эше

ЭЛЕКТРОМАГНИТ КЫРЛАР ҺӘМ КЕШЕ ЭКОЛОГИЯСЕ

Иванов Кирилл, 11-нче сыйныф
Сидоров Максим, 10-нчы сыйныф
Юнәлтүче оешма:

Эколого-биологик балалар үзәге, Казан шәһәре. Фәнни җитәкчеләр:
ө.б.у. I категория Макарова И.Н.,
б.ф.к., доцент КФУ Сидоров М.Ю.

Казан 2022

Кушымта 4
М. И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбенең
VII Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе

**Электрон презентацияне әзерләү һәм тәкъдим итү таләпләре**

I. Электрон презентациянең структурасы

1. Тикшеренү эшенең исеме, юллаучы оешма исеме, докладчының һәм фәнни җитәкченең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме.
2. Тикшеренү эшенең төп максаты һәм бурычлары.
3. Тикшеренү эшенең төп этаплары.
4. Йомгаклау (нәтиҗә чыгару).
5. Кулланылган чыганаклар исемлеге.
6. Тикшеренү эшен язуда булышучыларга рәхмәтләр белдерү.

Слайдлар тәртибе доклад төзелешенә туры килергә тиеш.

II. Электрон презентацияне әзерләү

1. Әзерләү өчен бердәм стиль кулланыла (презентациягә туры килми торган стильләрдән баш тартыгыз).
2. Тикшеренү эшенә туры килә торган төсләр кулланыла (бер слайдта 3-тән артык төс булырга тиеш түгел: берсе фон өчен, баш бит һәм текст өчен). Фон һәм текст өчен контраст төсләр кулланыла.
3. Слайдта бары тик докладчының телдән сөйли торган төп сүзләре һәм җөмләләре булырга тиеш, ә текст язылмый.
4. Шрифт күләме: баш бит пункты 24 – 25, текст пункты 18 – 36. Курсив, калын һәм декоратив шрифт бары тик текстның мәгънәсен аерыр өчен генә кулланыла.
5. Мәгълүматны күрсәтү өчен төрле рәвешле слайдлар кулланыла ала: текст, таблицалар, схемалар, графиклар, иллюстрацияләр. Һәр слайдның эчтәлеген күрсәткән исеме булырга тиеш.
6. Анимацияләр тыңлаучының игътибарын җәлеп итү өчен кулланыла. Төрле анимацион күренешләр фәнни эшнең эчтәлеген төгәлрәк күрсәтү өчен кулланыла ала, әмма алар мәгълүматнең эчтәлеген аңлуга комачауламаска һәм күп вакыт алмаска тиеш.

VII. Презентацияне тәкъдим итү таләпләре

1. Презентация файлы Microsoft PowerPoint 2007/2010, OS Windows стандарт форматында булырга тиеш.
2. Электрон презентацияләр Flash-җайланмасында тапшырылырга тиеш.